ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

№ 217

**КАРАР**

"27" март 2024 ел

«2024 елга халык өчен торак хезмәтләренә тарифлар турында» 2023 елның 15 декабрендәге 968 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«2024 елда Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы дәүләт һәм муниципаль торак фондының торак урыныннан файдаланган өчен түләү күләмен (аренда өчен түләү) һәм торак урыныннан файдаланган өчен түләүнең база күләмен (аренда өчен түләү) билгеләү тәртибе турында» 2024 елның 25 мартындагы 210 номерлы Спас муниципаль районы башкарма комитеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР ИТӘ:**

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитетының «2024 елга халык өчен торак хезмәтләренә тарифлар турында» 2023 елның 15 декабрендәге 968 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «2024 елга халык өчен торак хезмәтләренә тарифлар турында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитетының 2023 елның 15 декабрендәге 968 номерлы карарына 2 нче кушымтаны шушы карарга кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында урнаштырырга (//http:pravo.tatarstan.ru) «Новая жизнь»- «Яңа тормыш район газетасында.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны инфраструктура үсеше буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Спас муниципаль районының
Башкарма комитеты җитәкчесе

В.А. Осокин

Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның ____ мартындагы ____ номерлы карарына кушымта.

**МУНИЦИПАЛЬ ТОРАК ФОНДЫНЫҢ ТОРАК УРЫНЫННАН ФАЙДАЛАНГАН ӨЧЕН ТҮЛӘҮ КҮЛӘМЕ (АРЕНДА ӨЧЕН ТҮЛӘҮ)**

| **Түләү исеме** | **Хезмәтне үлчәү берәмлеге** | **Календарь белән бүленгән үлчәү берәмлеге өчен түләү күләме (рубльдә)** | |
|---|---|---|---|
| | | **2024 елның 01 гыйнварыннан 2024 елның 30 июненә кадәр** | **2024 елның 01 июленнән 2024 елның 31 декабренә кадәр** |
| 1 | 2 | | |
| муниципаль торак фондының торак урыныннан файдаланган өчен түләү күләме (аренда өчен түләү) | аена торак бинаның гомуми мәйданының кв. м. | 6-95 | 7-77 |